*Декабрь, 2020*

# *Гимназия сулышы №2*

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

## Ел укытучысы -2021

Октябрь аенда  гимназиянең физкультура укытучысы Вагизова Лилия Мөнир кызы Түбән Кама муниципаль районы



укытучылары арасында  уздырылучы “Ел укытучысы -2021”конкурсында катнашты. Лилия Мөнир кызы яшь белгеч  буларак , укучылары белән гимнастика күнегүләре буенча  мастер –класс күрсәтте һәм “ Ел ачылышы” номинациясендә җиңүче булды. Әлеге конкурста шәһәр һәм район мәктәпләреннән 25 укытучы катнашты. Лилия Мөнир кызын котлыйбыз  һәм укытучылык эшендә яхшы нәтиҗәләргә ирешүен телибез!



## Инглиз теле бәйгесе

Октябрь аенда  инглиз теле буенча бер төркем 5-11 нче сыйныф укучылары “Фән нигезләре буенча дөньякүләм олимпиада”да



катнаштылар. Алар дистанцион рәвештә инглиз теле буенча белемнәрен тикшерделәр. “Күңелле инглиз   теле” түгәрәге җитәкчеләре Илюкова И.И. һәм Исламова Г.А. укучыларга I , II нче дәрәҗәдә Диплом нар  тапшырдылар. Яркеев Илья

## Безнең анонс!

***2021-22 нче уку елында Түбән Камада «Мәктәп укучыларына һөнәр сайлауда юнәлеш бирүне тормышка ашыру”( “Түбән Каманың һөнәр дөньясы”) программасы эшли. Бу 8-9 нчы сыйныф укучыларына шәһәрнең колледж, техникумнары белән танышып  төрле проектларда катнашу мөмкинлеге бирә.***

Кадерле укучылар, газетабызның алдагы битендә язмада  шул хакта укыгыз!

## Нинди һөнәр сайларга?



9 сыйныф укучылары октябрь-декабрь айларында “Мир профессий Нижнекамска” программасы буенча шәһәрнең урта һөнәри белем бирү колледжларында экскурсиядә, мастер –классларда катнаштылар. Бу программаның максаты- укучыларга һөнәр сайлау буенча юнәлеш бирү. 9 В сыйныфы

## Хәйрия акциясе



Гимназиядә төрле хәйрия акцияләре үткәрү матур куренеш. Шуларның берсе йортсыз калган этләр, мәчеләр яшәүче приютка азык белән ярдәм итү.



Ноябрь аенда узган бу мәрхәмәтле акциядә 5 а,б,в,г, д сыйныфлары актив катнашты. Укучылар

укучысы Лузик Алексей Түбән Кама политехника колледжыннан “Электромонтаж” компетенциясе буенча Казан шәһәрендә үткәрелгән «World Scils” регионара чемпионатта катнашты. Алексей үз командасы белән III урын яулады. Алексейны котлыйбыз!



Гимназиянең 9 Д һәм 8 Г сыйныфларыннан бер төркем укучы ИЭ и УП уку йортында булдылар. Алар уку йорты белән таныштылар. Бакирова Алия

жыйган азык дүрт аяклы дусларыбызга зур ярдәм булачак, әлбәттә.

## Өр яңа китап укучылар



« Салават күпере», « Непоседа», «Сабантуй», «Фантазёры»,«Колобок» - менә шундый журналлар белән кызыксындылар 1 Д сыйныфы укучылары. Аларны гимназия китапханәчесе Резеда апалары өр-яңа китап укучылары буларак кунакка чакырган иде. Ул балаларга Ак барс банкы тарафыннан кайткан татарча-русча-инглизчә язылган китаплар да бүләк итте. Беренчеләр китапханәне һәм китапханәче Резеда апаларын бик ошаттылар. Ячменева Анастасия

# Язучы белән очраштык



Вәсимә Габдулла кызы Сәлахова-язучы, шәһәребезнең “Кама таңнары” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы. Ул безнең гимназиядә еш кунакта була. Күптән түгел Вәсимә Габдулла кызы 10 А сыйныфы укучылары белән очрашуда булды. Ул укучыларга үзенең яңа гына чыккан “Көмеш җепләр чыңы” китабын тәкъдим итү кичәсе булды. Язучы белән китап трында фикер алышу булды, укучылар Вәсимә Габдулла кызына иҗаты турында сораулар бирделәр.



Очрашуны оештыручы гимназия укытучысы Осипова Гөлчәчәк Талип кызы укучылар исеменннән Вәсимә Габдулла кызына рәхмәт белдерде, иҗади уңышлар теләде.  Хуҗҗәтов Адель

**Иҗат сөюче укучылар**

Кадерле укучылар, газетабыз битләрендә урын алган  кызыклы мәкаләләрне, фотоларны  кем эшли дип уйлыйсыз? Менә алар - Баринова Виктория, Ширяева Мария, Горохова Полина һәм Хуҗҗәтоа Адель.       Уку чиреге дәвамында алар гимназиядә үткәрелүче чаралар турында мәгълүмат җыялар , яхшыларын сайлыйлар, иҗади яктан эшкәртәләр. Фотода “Туган телне сөючеләр” түгәрәгенең чираттагы утырышы сурәтләнгән. Гайфуллин Инсаф



**Тарих эзләре музейда**

Гимназия музее 2005 нче елдан бирле эшли.Төбәк тарихына, крестьян хуҗалыгына караган экспонатлар, милли киемнәр , чиккән сөлгеләр, борынгы эш кораллары гимназиядә белем бирүче укытучылар, хезмәткәрләр, укучыларның



әти-әниләре катнашында тупланган. Экскурсовод Паненко Аида музейга килүче укучыларга һәр экспонат турында кызыклы һәм мавыктыргыч мәгълүмат җиткерә.  Качаева Диана

## Тегермән турында хикәя

Бер ямьле табигатьле авыл янындагы тау башында җил тегермәне булган. Бу тегермәнгә ничә яшь икәнен бары тик җилләр генә белгән. Аның ишеге кыйшайган, ташлары мүкләнгән, әйләнә - тирәсен кычыткан, әрекмән басып киткән.

Ә бит бу җил тегермәненең гөрләп торган яшь чагы булган! Көчле җилләр искән көннәр тегермән өчен гел бәйрәм кебек булган, чөнки ат арбаларына зур капчыкларга бодай, арыш төяп авыл агайлары он тартырга килгән. Ә тегермәнче бабай тегермән канатларын эшкә җиккән. Авыл агайлары капчыкларына ап-ак он тутырып өйләренә ашыккан. Һәр өйдә хуҗабикәләр пешергән тәмле күмәч , бәлеш исе чыккан.

Билгеле инде, җил көн дә исмәгән. Андый көннәрдә тегермән тынып калган. Тегермәнче бабай үз эшләре белән авылга киткән. Тегәрмәндә яшәүче тычканнар, ярыкларда калган бөртекләрне ашап, рәхәтләнеп тамак туйдырганнар. Җилле көннәрдә тегермән кешеләргә хезмәт иткән. Шулай ел артыннан ел узган…

Бервакыт тегермән тирәсе бөтенләй тынып калган. Көчле җилләр иссә дә, капчыклар төялгән арбалы авыл агайлары күренмәгән.

Җил тегермәне бу хәлгә бик гаҗәпләнгән, ул бик күңелсезләнгән. Көннәрдән бер көнне иске тегермән авыл ягында ниндидер мотор тавышына ошаган гүләү ишеткән. Яңа электр тегермәне икән ул! Хәзер авыл кешеләре капчык тулы ашлыкларын шунда ташыйлар икән. Ул тегермәнгә җил кирәкми икән шул .

Иске җил тегермәне моны белгәч бик боеккан, чөнки аның ишеген ачып керүче кеше булмаган.
Көз айлары үтеп кыш җиткән, аннан ямьле яз килгән. Матур язның бер көнендә иске тегермән янына кешеләр килгән. Алар кызып-кызыпниләр турындадыр сөйләшәләр икән. Иске тегермән игътибар белән тыңлаган. Кемнеңдер башына иске тегермәндә чәйханә ачу фикере туган. Күпмедер вакыттан соң тегермән янына йөк машиналары килеп туктаган. Кирпечләр, такталар, тәрәзәләр китергәннәр . Авыл агайлары тегермән янындагы күперне яңарталар. Балта осталары тегермәнгә яңа канатлар ясап куялар. Тегермәннең эчке як стеналарына рәссамнар матур рәсемнәр ясыйлар. Шулай итеп, иске җил тегермәненең яңа күңелле тормышы башлана. Тегермәндәге чәйханә юлчыларның яраткан ял итү урынына әверелә. Олысы, кечесе чәйханәгә туктап тәмле коймак, бавырсак , өчпочмаклар белән сыйланалар. Тамак ялгап алгач тирә-якның матурлыгын карап хозурланалар.

Татар халкында « Иске яңаны саклый», дигән әйтем бар. Бу әйтемнең нең хикмәте шунда: гасырлардан килгән тарихны онытмасак иде !
Бакирова Алия



## *Тиздән каникуллар!*




2020-21 уку елының II-чиреге тәмамланды. Газета укучыларыбызны Яңа  ел белән котлыйбыз!Яңа елны безгә 2021 елның символы - Ак металл үгез алып килә. Короновирус авыруы белән тарихта эзен калдырган кәбисә ( весокосный) елыннан соң, 2021 ел тыныч булыр дип фаразлана.
Тыштан тәкәббер булып күренсә дә,Үгезнең уңай яклары да күп. Ул- тәвәккәл, юмарт, киң күңелле.
Кадерле укучылар! Сезгә Яңа елда сәламәтлек, белем үрләрен яулауда уңышлар, уйлаган хыялларыгызның тормышка ашуын телибез! Кышкы ялыгыз күңелле һәм файдалы узсын! Саф һавада күбрәк йөрегез! Тауда яисә шугалакта шуганда куркынычсызлык кагыйдәләре турында онытмагыз!
Исламова Карина

**Кадерле укучыларыбыз!**
**Әгәр сезнең безгә тәкъдим итәрлек яңалыкларыгыз булса хәбәрләрегезне 302001035@edu.tatar.ru электрон почтасына җибәрегез! Редактор Хуҗҗәтов Адель.**
**Проект җитәкчесе Шарапова Н.Н.**

**Чыршы әйләнәсендә**
**Роберт Миңнуллин**
Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә – тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч булачак
Котлаулар да, бүләк тә!
Яңа елда чынга ашар
Теләгән һәр теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез!



